# КАРАР
## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Мәрәтхуҗа авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11 нче декабрь 2021 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 нчы елның 11 нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Кече Мәрәтхуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Кече Мәрәтхуҗа авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокыр ремонты, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);;

- зират коймасы (төзелеш материаллары сатып алу);

- Кече Мәрәтхуҗа авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);;

- Кече Мәрәтхуҗа авылы территориясен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 127 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 70 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 70 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенә керүче Кече Мәрәтхуҗа авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Кече Мәрәтхуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Кече Мәрәтхуҗа авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокыр ремонты, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);;
- зират коймасы (төзелеш материаллары сатып алу);
- Кече Мәрәтхуҗа авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);;
- Кече Мәрәтхуҗа авылы территориясен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Кече Мәрәтхуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Кече Мәрәтхуҗа авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокыр ремонты, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);;
- зират коймасы (төзелеш материаллары сатып алу);
- Кече Мәрәтхуҗа авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);;
- Кече Мәрәтхуҗа авылы территориясен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Гагарин урамы, 38, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге
башлыгы: А.Г. Җиһаншин